Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

23 ноябрь, 2023 ел № 282

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләренең бәяләрен билгеләү тәртибенә җир кишәрлеген торглар үткәрмичә сату-алу шартнамәсе төзегәндә үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып баруы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2016 елның 15 августындагы 53 номерлы карары белән расланган торглар үткәрмичә генә җир кишәрлеген сату-алу шартнамәсе төзегәндә (Советның 2021 елның 20 маендагы 74 номерлы, 2021 елның 10 июнендәге 84 номерлы, 2022 елның 08.09.183 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Тәртипкә кушымтада 10 пунктта «бакчачылык» сүзләреннән соң «үз ихтыяҗлары өчен» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов